


2024 елның 27 мартында “Педагог 13.” мәйданчыгында туган телне (мокша, эрзә, татар) һәм туган әдәбиятны укытуда, система булдыручы үзәк буларак, традицион Россия кыйммәтләре” төбәкара семинары узды. Әлеге семинарда Мордовия Республикасы һәм мордва халкы тупланып яшәгән төбәкләрнең мәгариф оешмаларыннан 40 туган тел һәм әдәбият педагогы катнашты.

Россия Федерациясендә Гаилә елына багышланган семинарның максаты - туган телне һәм әдәбиятны укытуның заманча практикалары турындагы тәҗрибәне диссеминацияләү.

Үзәкнең этномәдәни белем бирү лабораториясе модире *Наумова Елена Михайловна* “Традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау – бу үсеп килүче буынны тәрбияләүнең төп бурычларының берсе”, – дип билгеләп үтте семинар модераторы. Төбәкара семинарда катнашучыларга сәламләү сүзе белән “Педагог 13” ректоры *Татьяна Васильевна Самсонова* үзенең чыгышында гаилә һәр кешенең тормышында иң мөһиме булуын билгеләп үтте. Монда мәхәббәт, хөрмәт, кайгырту, зирәклек һәм җаваплылык өйрәтелә.

Төбәкара семинар эшендә «Россия Федерациясе халыкларының туган телләре федераль институты»ның этномәдәни белем бирү һәм конкурс эшчәнлеге бүлегенең әйдәп баручы белгече *Марина Мансур кызы Салихова* (Мәскәү шәһәре) катнашты. Марина Мансур кызы хезмәттәшләренең игътибарын туган телләр институтының традицион кыйммәтләрне, тел күпторлелеген һәм мәдәни мирасны саклау коралы буларак проектларына юнәлтте.

Шулай ук семинар эшендә Мордовия Республикасы мәгариф оешмаларының түбәндәге педагоглары катнашты:

- *Ольга Викторовна Кочеваткина*, филология фәннәре кандидаты, Саранск шәһәре 28 нче урта гомуми белем бирv мәктәбе укыту-тәрбия эше буенча директор урынбасары, әрзә теле укытучысы: “Мордва халкынын мифология-сен ойрәнv мисалында укучыларны Россиянен традицион кыйммәтләренә жәлеп итv”;
- *Марина Николаевна Миронова*, рус теле һәм әдәбияты, мордва (мокша) теле укытучысы Советлар Союзы Герое М.П.Девятаев исемендәге Саранск



шәһәре 15 мәктәбе: “Гаилә традицияләре дәресләрдә һәм дәрестән тыш эштә әдәбият укыту-чысынын тәрбия эшчәнлегенен бер аспекты буларак”;
- *Равиль Харис улы Казанбаев*, Мордовия Республикасы Кадошкино урта гомуми белем бирv мәктәбенен тарих укытучысы: “XIX гасыр ахырында XX гасыр башында Пенза губернасынын Инсар оязе татар-мишәрләренен мәгариф системасы”;
- “Ел укытучысы – 2024” нен 10 апреленә кадәр vтә торган Мордовия муниципаль туры катнашучылары - *Юлия Рэшит кызы Рамазанова* белән *Земфира Хафиз кызы Мангутова*, Саранск шәһәренен 11нче урта мәктәбе башлангыч сыйныфларда татар теле укытучылары: “Кече мәктәп укучыларын дәрестән тыш дәресләрдә әхлакый тәрбияләv һәм укыту”;
- *Алмаз Кериш кызы Янгляева*, Ләмберә районынын 1нче номерлы урта мәктәбе татар теле укытучысы: “Туган татар телен һәм милли традицияләрен саклауда һәм vстерvдә гаиләнен роле”;
- *Зульфия Захир кызы Сюбаева*, Ләмберә районынын 1нче номерлы урта мәктәбендә педагог-оештыручы: “Безнен гаиләдә туган тел”;
- *Рауза Мукаддяс кызы Юмаева*, Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбенен татар теле һәм әдәбияты укытучысы: “Гаилә буыннарнын озлексез бәйләнеше”.

Тобәкара семинарда катнашучылар мондый нәтижәгә килделәр: Ватаныбызнын киләчәге Россия яшьләренен игелек, намуслылык, гаделлек, хезмәт соючәнлек һәм Ватанга хезмәт итәргә әзерлек принципларында тәрбияләнvенә бәйле.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**